Ютазы муниципаль районы
Иске Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Тукай шигъриятендә табигать сурәте



Гыймаева Зөлфия Фәһим кызы,
беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Максат һәм бурычлар :

-Тукай шигъриятендәге табигатьне сурәтләү алымнарын табарга өйрәтү һәм аларның матурлык тудырудагы ролен билгеләү;

- яңа технологияләр кулланып, табигать күренешләрен анализлауның яңа алымнары турында мәгълүмат бирү;

-бөек шагыйребез Г.Тукай әсәрләре аша табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, аның гүзәллеге белән соклану хисләре уяту.

Җиһазлау: проектор, экран, презентация, Г.Тукай шигырьләре һ.б.

# Туган авыл

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным- тәнем белән.
Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем.
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.
Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер: кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кая торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

1. Шигырьне тыңлаганда сезнең күңелдә нәрсә туды?
Хис.

2.Нәрсә ул хис?
Хис – дөнья вакыйгаларына күңел белән бәя бирү ул.

3. Хис туу өчен нинди шартлар кирәк?
Хис туу өчен сәбәп кирәк. Хисне тудыручы сәбәп – хиснең эчтәлеге була.

4. Нинди хисләр була?
Кайгы, шатлык, ярату, нәфрәт, горурлык, кимсенү, соклану, мәхәббәт хисләре.

5. Ә бу шигырьдә нинди хисләр чагылыш таба?
Туган як матурлыгы белән соклану, горурлану, шатлану, тарихыбыз белән кызыксыну хисләре, тарих күз алдыннан уза.



**Чагыштыру- бер предметны яки күренешне икенче предметка охшатып әйтүне белдерә.**

**Чагыштырулар. Алар ап-ак балыклар <u>күк</u>**
**Йөзәләр иртәдән кичкә кадәр.**
**Шунда туңып бетмичә**
**Ярга чыкмыйлар һич тә.**
**(Җәй көнендә)**
**Карны җиңгән <u>күк,</u>**
**Төшә җиргә**
**Тонык ай яктысы;**
**Ай да куркынган <u>шикелле</u>: бер сары, бер ак төсе.**
**(Буран)**
**Саргая таллар,**
**Усаклар, алмагачлар һәм каен.**
**Хәстә <u>төсле</u>, арта**
**Сары төс аларда**
**Көн саен.**
**( Чыршы)**

**Йоклый шунда йолдызлар да өелеп**
**Оядагы йоклап яткан <u>кошчыклардай.</u>**
**(Ай һәм кояш)**
**Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,**
**Яшел хәтфә <u>шикелле</u> итә җем- җем.**
**(Көз)**
**Бик хозур! Рәт- рәт тора, гаскәр <u>кеби,</u> чыршы, нарат.**
**Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.**
**(Шүрәле)**

**Эпитет- күренеш һәм предметның сыйфатын, аерым билгеләрен белдерүче сурәт. Ул җөмләне аеруча бизәп тора һәм аны табарга да җайлы.**

Эпитетлар

Кырга ак кардан
Юрган ябылган...
Язның айлары
Апрель, майлары.
Бик матур сызылып
Аткан таңнары.
(Җир йокысы)

Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
(Көз)

Ул авылның -һич онытмыйм,- һәр ягы урман иде
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
(Шүрәле)

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.
(Җәйге таң тәтирәсе)

**Г.Тукай шигъриятендәге калын урманнар, сайрар кошлар, хуш ис бөркегән чәчәкле болыннар җир йөзенең башка төшләрендә юк сыман.**

**Чыннан да юк, моны Тукай гына халыкча итеп сурәтли алган. ( “Иртә”, “Җир йокысы”,“Ай һәм кояш”, “Кояшка бер сүз”, “ Туган авыл”, “Туган җиремә”, “Шүрәле” һ.б)**

**Юкка гына Тукай үз иҗатында туган як табигатен шулай сурәтләмәгән!**

**Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар;**
**Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне адәм бар! (Яратырга ярый)**


ArtNow.ru


ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН ЗУР
РӘХМӘТ!